СОВЕТ
ЯНГА - САЛСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д.18, с. Янга-Сала,
Арский муниципальный район, 422011

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢАСАЛА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урам, 18 йорт, Яңасала авылы,
Арча муниципаль районы, 422011

Тел. (84366) 57-2-10, факс (84366) 57-2-10. E-mail: Yns.Ars@tatar.ru www.arsk.tatarstan.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**

# КАРАРЫ

**30 октябрь 2023 ел** **№ 1**

**Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Яңасала авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Яңасала авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге уставының 25 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы **Карар бирде**:

1. Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Яңасала авылында Яңасала авылы, Үзәк урам, 20 нче йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2023 елның 15 ноябренә 10 сәгать 00 минутта халык җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Яңасала авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы?

- юл-урам челтәре нигезен вак таштан каплау, Яңасала авылы Клуб урамының 19 нчы йортыннан алып 31 нче йортка кадәр.

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»»

3. Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Яңасала авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Яңасала авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны халык күп җыела торган урында мәгълүмат стендында ТР, Арча районы, Яңасала авылы, Үзәк урам, 18 нче йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Яңасала авыл
җирлеге башлыгы А.И. Сафин